**Манзарас авыл җирлеге башкарма комитеты**

**Карар**

**2023 елның 27 феврале** **№23**

Манзарас авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендәге 16 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярилык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәгендәге 394-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Манзарас авыл җирлеге башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыяри (волонтер) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыяри (волонтер) оешмалар белән хезмәттәшлеге тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендәге 16 номерлы карарына (2022 елның 24 октябрендәге 36 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырыла:

«- медицина ярдәме күрсәтүче оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция) һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда булышлык күрсәтү.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Манзарас башкарма
комитет җитәкчесе Р.Г.Хәбибуллина

ОГРН 1061675010869
ИНН 1623008419